СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2022 г. Заинск № 91

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 10 ноябрендәге 72 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 10 ноябрендәге 72 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.3.1 пунктча белән тулыландырырга:

«2.3.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы белән билгеләнгән.»;

1.2. 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан күрсәткечләре, индикатив күрсәткечләр

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча төп күрсәткечләр:
Максатчан әһәмияттәге төп күрсәткечләр (%)
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә урнашкан төзекләндерү объектларына контрольдәге затлар тарафыннан кылынган төзекләндерү өлкәсендәге законнарны бозу нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә закон белән саклана торган кыйммәтләрнең гомуми күләменә карата китерелгән зыянның нисбәте түбәндәге формула буенча исәпләнә:

КП = (Вобщ./ ВРП) х 100,

монда:

Вобщ. – контрольлек итүче затлар тарафыннан төзекләндерү өлкәсендәге законнарны бозу нәтиҗәсендә муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан төзекләндерү объектларына китерелгән зыян (мең сумнарда);

ВРП – муниципаль берәмлек территориясендә закон белән саклана торган кыйммәтләр күләме (мең сумнарда).
Төп күрсәткечнең кыйммәтен исәпләү өчен хисап чоры булып календарь ел тора.
Төп күрсәткечнең максатчан кыйммәте ел саен төп күрсәткечнең кыйммәтен 1% ка киметүдән чыгып билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча индикатив күрсәткечләр.
1) хисап чорында үткәрелгән тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны (алга таба - КНМ);
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
4) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының һәм үзара хезмәттәшлек чараларының гомуми саны;
5) хисап чорында КНМның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек белән үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында алдан кисәтүләр саны;
9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
10) хисап чорында нәтиҗәдә административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) хисап чорында прокуратура органнарына контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында җибәрелгән гаризалар дан прокуратура органнары килештерүдән баш тартканнары саны;
14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
15) хисап чоры ахырына куркынычлык категориясенә кертелгән һәр категория буенча исәпкә алынган контроль объектлары саны;
16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдәге затлар саны;
17) хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдәге затлар;
18) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;
19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау вакыты бозылган шикаятьләрнең саны;
20) хисап чорында судка кадәр тәртиптә аларны карау нәтиҗәләре буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча йә өлешчә юкка чыгару, йә контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) дөрес түгел дип тану турында контрольдәге затлар тарафыннан бирелгән шикаятьләр саны;
21) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан суд тәртибендә контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында гаризалары саны;
22) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан суд тәртибендә контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерелгән гаризалардан аларны канәгатьләндерү турында карар кабул ителгәннәре саны;
23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас рәвештә бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.»;
1.3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«1 кушымта
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
2022 елның "21" 04 2022
91 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН.

**Төзекләндерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты тарафыннан планнан тыш тикшерүләр үткәрү зарурлыгын билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Якын-тирә территориядә яки гомуми файдаланудагы башка территорияләрдә җитештерү һәм куллану калдыклары булу.

2. Бина, төзелмә, корылмалар фасадларында, шулай ук башка төзекләндерү элементларында һәм җәмәгать урыннарында рөхсәт ителмәгән язулар яки рәсемнәр булу.

3. Якын-тирәдәге территорияләрдә гражданнарның иркле һәм куркынычсыз үтүенә комачаулый торган киртәләр булу.

4. Биналар, корылмалар түбәләрендә боз сөңгеләре булу.

5. Инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус билгеләрне, язуларны юк итү яки зыян китерү.

6. Рөхсәтсез җир эшләре башкару.

7. Җир казу һәм ремонт эшләре башкарганда биналарга якын килү һәм аңа керү, шулай ук ишегалларына машина белән керүдә, җәяүлеләрнең иминлеген һәм җәяүлеләрнең куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итүдә киртәләр тудыру.

8. Яшелләндерелгән территорияләрдә (шул исәптән газоннар, чәчәклекләр һәм үләнчел үсемлекләр үсә торган территорияләр), балалар һәм спорт мәйданчыклары, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чаралары урнаштыру.

9. Гомуми файдаланудагы территорияләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм кош-кортларны йөртү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**